БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!
СОВЕТЛАР СОЮЗЫ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕ ЭШЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ ӘЗЕР БУЛ!




Яшь ленинчы

ЧӘРШӘМБЕ,
10 АПРЕЛЬ,
1968 ЕЛ.
1924 елның 10 октябреннан чыга.
Бәясе 1 тиен.

№ 28 (1831).

ВЛКСМның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ В. И. ЛЕНИН ИСЕМЕНДӘГЕ ЛЕНИН ОРДЕНЛЫ БӨТЕНСОЮЗ ПИОНЕР ОЕШМАСЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА СОВЕТЫ ОРГАНЫ

Олар „Космонавтлар урамыннан"





Рафис Лотфуллинның этисе — очучы. «Ватан канатлары» газетасында аның батырлыгы турында мәкалә басылып чыкты. Ул, самолеты зарарлануга карамастан, аны исән-сау аэродромга төшерә алган. Рафис бу турыда дулкынланып укыды. Бераздан: «Әти, ә син космонавт була алыр идеңме?» —дип сорады ул, кызыксынып. «Космонавт булу өчен яшьтән үк үзеңдә бик күп уңай сыйфатлар тәрбияләргә кирәк шул, — диде этисе. — Әйтик, менә без футбол уенын карыйбыз, ди. Бер команда һөҗүм итә. Ләкин туп һаман капкага керми. Соңгы удар төгәл түгел... Әгәр космонавтлар да үзәк һөҗүмче кебек ялгышсалар яки каушап калсалар, никадәр галимнәрнең һәм эшчеләрнең хезмәте әрәм булачагын күз алдына китерәсеңме? Менә шуңа күрә дә теләсә кем космонавт була алмый...»

Рафис этисенең сүзләрен игътибар белән тыңлады, ул сөйләгәннәрне иптәшләре белән уртаклашты. Аларның пионер отряды исемсез иде әле. Алар Космонавтлар исемендәге отряд дип аталыр өчен көрәшергә карар иттеләр...


Иртәгә язгы каникуллар башланасы көн иде. Дәресләр тәмамлангач, дүртенчеләр өйләренә таралырга ашыкмадылар. «Әйдәгез, классыбызны чиста итеп юып калдырыйк!» — диделәр алар. Ике рәтнең укучылары тиз генә эшкә керештеләр. Ә калган ике рәтнең кызлары Оля, Ира Гармонова һәм Ира Чубароваларның идән юып мәшәкатьләнәселәре килмәде. «Әйдәгез, малайлар, үзебез генә юабыз. Оят булсын әле үзләренә», — диде Мурат. «Ләкин аларны барыбер кайтармаска кирәк. Безнең юган-

(Ахыры 2 нче биттә.)





12 АПРЕЛЬ— КОСМОНАВТИКА КӨНЕ



СОВЕТЛАР Союзыннан җибәрелгән Җирнең беренче ясалма иярчене бу. Ул диаметры 58 сантиметр, авырлыгы 83,6 килограмм булган шардан гыйбарәт иде. Иярчен Җир тирәли 1480 әйләнеш ясады һәм 60 миллион километрга якын юл үтте. Ул кайчан җибәрелде?

(Рәсемнәрне карау тәртибе — аскы уң яктан сулга һәм өскә таба.)

ӘМОНЫСЫ — Җирнең икенче ясалма иярчене. Ул Советлар Союзыннан 1957 елның 3 ноябрендә җибәрелде. Аңа эт утыртылды. Очышның максаты тере организмга Галәмдә очуның тәэсирен сынау иде.

Әлеге этнең исемен әйтегез.

* * *

ҖИРНЕҢ өченче ясалма иярчене. Аның барлык авырлыгы 1327 килограмм иде. Иярчен Җир тирәли 450 миллион километр—беренче ясалма иярченгә караганда 7 тапкыр артык юл үтте.

* * *

АЙНЫҢ безгә күренми торган ягын беренче булып фотога төшергән һәм Җиргә тапшырган автомат станция «Луна—3» бу. Аның кайчан җибәрелүен әйтеп карагыз.


* * *


1959 елның 12 сентябрендә Советлар Союзыннан җибәрелгән планетаара автомат станциясе «Луна—2» ике көннән соң Ай өслегенә барып төште. Ул Җир иярченендә читтән килгән беренче «кунак» иде.


Автомат станция Айга нәрсә алып менде?

* * *

СОВЕТЛАР Союзыннан «Космос» исемендәге 200 дән артык ясалма иярчен җибәрелде. Аның беренчесе шундый иде.









Академик С. П. Королев һәм Ю. А. Гагарин.


Олар „Космонавтлар урамыннан

ны тик карап торсыннар»,— дип куйды Валера. Малайлар идәнне ялт итеп юып чыгаргач, кызларга чыннан да уңайсыз булып китте...

Инде отряд исем алырга лаек, дип торганда гына тагын бер «ЧП» булып алды. Шулай беркөнне Юра дәрестә шигырь сөйләгәндә ялгышты. Наташа ручка белән аңа төртеп куйды. Ә Игорь, комачаулама дип, Наташага әйтим дигәндә ялгыш орынып кызның көндәлеген төшереп җибәрде. Наташа зәһәрләнеп Игорьга китап белән кундырды. Боларның барысын да күреп өлгергән укытучылары Лариса Михайловна малайның көндәлеген алып аның тәртипсезлеге турында язып куйды. Ә Наташа бу минутта Игорьга телен күрсәтеп: «Шулай кирәк сиңа!» — дип утырды.

Отряд Наташаның тәртибе турында дәрестән соң калып сөйләште. «Без Космонавтлар исемендәге отряд дип аталыр өчен көрәшәбез. Шуңа күрә алар кебек намуслы булырга да тиеш»,— диделәр пионерлар. Наташа башын түбән иеп утырды, үзенең гаепле булуын аңлады. Соңыннан укытучыдан гафу үтенергә сүз бирде...

121 нче мәктәпнең IV Г классында укучы бу пионерларның күбесе Казанның иң матур җирендә урнашкан Космонавтлар урамында яшиләр. Аларның һәркайсының үзенә генә хас сыйфатлары бар. Рамил — кыю, тапкыр, Алик — дөресен әйтергә ярата, Ира Артемьева — тырыш, Ира Гармонова — күп сөйли, Ри-





нат — шаян, төрле коллекцияләр җыя, ә Миша — кызларны яклый. Әмма аларның барысын да берләм, дус пионер отряды һәм космонавтлар кебек булу омтылышы берләштерә.

М. ХӘБИБУЛЛИН.
Автор фотосы.

10 апрель, 1968 ел.
2—3 битләр.


КЕШЕЛӘР үзләре яши торган планета турында күптән уйланганнар. Берәүләр аны зур океанда йөзеп йөрүче кит өстендә, икенчеләр гигант ташбака өстендә тора дип исәпләгәннәр. Ә аның формасы яссы дип уйлаганнар. Магелланның дөнья тирәли сәяхәте, Галилей, Коперник кебек бөек галимнәрнең ачышлары Җирнең шар формасында булуын раслады лар.

Читтән караганда ул безгә ничек күренә икән? Дөньяда беренче булып бу сорауга совет космонавтлары җавап бирделәр. Г. С. Титов үзенең очышы вакытында Җир шарының беренче фоторәсемен алып кайтты. Менә нинди икән ул Җир! Аның беркадәр өлешен караңгылык каплаган. Бу — Җирнең кояшка каршы ягы. Анда төн. Кешеләр йоклыйлар. Ә якты өлешендә көн. Кешеләр кырларда эшлиләр, мәктәпләрдә укулар бара, бүлмәләрдә утлар сүндерелгән.

Бу рәсем факт инде. Динчеләргә төрле уйдырмалар чыгарырга бернинди җирлек юк.

ӘМОНЫСЫ — Айның безгә күренми торган ягының беренче рәсеме. Аны 1959 елда совет планетаара автоматик станциясе төшереп алды һәм телевидение аппаратлары ярдәмендә Җиргә тапшырды.





Кечкенәдән космонавт булган



Юк, ул һәлак булгач кына түгел, бу турыда мин электән уйлана идем, һаман уйлана идем, уйларымны сезгә дә сөйлисем килә иде, кадерле дусларым.

Ул уйларым минем менә кайдан башланган иде.

1961 елның җәе иде бу. Июнь көннәренең берендә мәрхүм шагыйрь Шәрәф абый Мөдәррис иртүк безнең редактор янына кергән дә болай дигән:

— Беренче космонавт Юрий Гагарин әти-әнисе янына Гжатскига кунакка кайткан. «Правда»да язганнар. Әле ул көнләп шунда була ди. Җибәр син аның янына берәр кешеңне. Күреп, сөйләшеп кайтсын, укучылар өчен кызыклы материал булыр, — дигән.

Әшкә килүем булды, редактор кабинетына чакырдылар.

— Хәзер үк җыен да, Гжатскига чыгып кит. Гагаринны күреп, сөйләшеп, материал алып кайт, — диде миңа редакторыбыз.

Бер сәгать эчендә җыендым да самолет белән Мәскәүгә очтым. Иртәгесен сәгать дүрттә поезд белән Гжатскига барып җиттем. Вокзалдагы дежурныйдан Гагарин мондамы, дип сорадым. Анык кына әйтә алмыйм, монда бугай, диде.

Гостиницага урнаштым. Смоленскидан килгән бер ханым бар иде бүлмәдә. Минем ник килгәнемне белгәч, аның шулкадәр миңа ярдәм итәсе килде. Мин нишләргә белмәдем, әле иртә булса да, Гагариннар өенә, Ленинград урамына киттем. Ул йортны кешедән дә сорый торган түгел, ул бердәнбер йорт. Өр-яңа ул. Мин килдем дә бәләкәй капканы ачтым. Үзем дулкынланам. Кинәт кенә ишектән космонавт үзе килеп чыкса, нишләрмен?! Иплән кенә ишек алдына үттем. Верандалы, бер катлы зур кирпеч өй. Аһ, ишек бикле икән шул... Аптырап торам. Шулчак ишек алды түреннән юантык кына гәүдәле бер ханым килеп чыкты.

— Исәнмесез! Сез Анна Тимофеевна буласызмы? — дидем. Шулай булып чыкты, космонавтның әнисе булып чыкты. Ә космонавт үзе юк, ул ике генә көнгә кайткан булган икән, инде китеп өлгергән... Әти-әнисенә хөкүмәт салдырган яңа йортның ачкычын тапшырырга кайтканнар.

Ни хәл итәсең бит... Аны эзләп мин аннары Мәскәүгә киттем-китүен, табып, күрешеп, редакциянең заданиесен дә үтәдем, әмма аңарчы монда, Гжатскида, мин бәйнә-бәйнә космонавтның бала чагы белән таныштым.

Менә шул, аның бала чагы турындагы уйларымны уртаклашасым килә минем сезнең белән.

* * *

...Юраның, абыйсы Валентин, апасы Зоя кебек, мәктәпкә йөрисе, кечләрен алар кебек дәрес әзерлисе килә. Әтисе, Алексей Иванович, Юрага җидесе тулгач укырга керәчәген әйтә. Әмма укырга керү шатлыгын сугыш сөреме каплап китә. Балалар парта арасына кереп утырып, беренче хәрефләр белән танышырга да өлгерә алмыйлар, немецлар авылга якын ук килеп җитәләр.

Нәкъ шул көнне Юраның туган авылы Клушино өстеннән кызыл йолдызлы ике самолет очып үтә. Аның берсен фашистлар атып «яралаганнар». Ул авыл башындагы сазлыкка килеп төшкәндә генә очучысы җиргә сикерергә өлгерә. Икенче самолет шуннан ерак түгел болынга төшә: иптәшеңне авыр хәлдә калдырып китәргә ярыймы соң?!

(Ахыры бар.)
Саимә ИБРАҺИМОВА.


ЧИТТӘН ТОРЫП

Күпчелек укучылар е7-е5 йөрешен язып җибәрделәр. Партия дәвам итә.

Наил Мөхәммәтҗанов — укучылар

1. е2-е4 е7-е5;
2. Ag1-f3

Хәзер, дуслар, сезнең йөреш! Хатларыгызны тизрәк җибәрергә тырышыгыз.



Ярыш көндәлеге

АВЫЛЫБЫЗНЫҢ партия, комсомол, мәктәп, колхоз һәм пионер оешмаларының тарихын өйрәнергә! Комсомолның 50 еллыгына багышланган ярышка старт алганда пионерлар шундый йөкләмә алганнар иде.

Бу эшкә кызыл эзтабарлар штабы җитәкчелек итте. Штаб һәр отрядка конкрет задание бирде һәм аның үтәлешен тикшереп торды.

Күптән түгел кызыл эзтабарлар штабы отрядлар эшенә йомгак ясады. Нәтиҗәләр куанычлы. Кызыл эзтабарлар авыл тарихы, мәктәп тормышы турында истәлекләр, фотокарточкалар җыйганнар, авылдагы өлкән кешеләр белән очрашулар үткәргәннәр.

Кызыл эзтабарларны алда яңа эзләнүләр көтә.

Фәнзия ШӘМСЕТДИНОВА.
Баулы районы, Исергәп мәктәбе.

●

КАНИКУЛЛАРДА да, ял көннәрендә дә безнең мәктәп ишеге ябылып тормый. Без мәктәптә шахмат, шашка, теннис уеннары уйныйбыз, газета-журналлар укыйбыз, мылтыктан төз атарга өйрәнәбез.

Йөгерек һәм сәнгатьле итеп уку, матур язу буенча да ярышлар үткәрәбез.

Бу ярышларда һәр пионер бик теләп катнаша.

Наилә НИЗАМЕТДИНОВА,
звено вожатые.
Буа районы, Иске Тинчәле авылы.

●

УКУ елы башында булды бу сөйләшү. Комсомолның 50 еллыгына мәктәп тирәсен яшелләндерергә булдык. Һәр отряд эшкә керешге. «Пионер янчыгы» ачтык. Металл ватыклары, макулатура җыеп алган акчаны шул янчыкка сала бардык. Хәзер бу акчага гөл савытлары, чәчәк орлыклары һәм үсентеләре сатып алдык. Мәктәп бакчасында парник булдырдык. Анда 40 мең төптән артык чәчәк үсентесе үстерәчәкбез. Җәйкөз көне мәктәп тирәсендә аллы-гөлле чәчәкләр хуш ис таратып, тирә-якка ямь биреп утырырлар.

Мәктәп микрорайонын һәм үзебез шефлык итә торган балалар бакчасы тирәсен дә гөлбакчага әйләндерергә уйлыйбыз.

Валерий РЯЗАНОВ.
Казан, 31 нче мәктәп.

В. И. Ленин бүлмәләренә смотр бара

МӘКТӘБЕБЕЗДӘ хәзергә Ленин бүлмәсе юк. Ленинның 100 еллык юбилеена без аны булдырырга уйлыйбыз. Дружинада моңа зур әзерлек бара. Ильичның тормыш юлын, эшчәнлеген чагылдырган стендлар төзибез, «Ленин укулары» үткәрәбез. «Ленин булган урыннар буйлап» экскурсияләр оештырабыз. Әлбәттә, бу эшләр безгә Ленин турында күбрәк белергә ярдәм итәрләр.

Ленин бүлмәләренә смотрның I этабы өчен һәр отряд йөкләмә кабул итте. Мәсәлән, безнең V Б класс пионерлары һәрберсе 10 кг тимер, 5 кг кәгазь, 50 кг көл җыеп тапшырырга һәм урамнарны яшелләндерүдә катнашырга булдылар.

Азат САДРЕТДИНОВ.
Октябрь районы, Күлбай Мораса урта мәктәбе.

* * *

МӘКТӘПТӘ Ленин бүлмәсе моннан берничә ел элек оешкан иде инде. Без анда пионер сборлары, экскурсияләр үткәрәбез. Ленинның пластинкага язылган речьләрен тыңлыйбыз. Авылыбызның атаклы кешеләре белән очрашулар да шушы бүлмәдә була.

Ленин бүлмәсендә алты яшьлекләр өчен махсус кичәләр оештырабыз.

Сания КӘРИМОВА.
Чүпрәле районы, Яңа Чокалы мәктәбе.


Мәк чәчәге



Безнең бакчаны матурлап
Балкып утыра бер мәк,
Әйтерсең ул яңа тегеп
Кигән ал ефәк күлмәк.

Мин теләп аны өзәргә
Китергән идем учны:
— Тимә, тимә! — дип бал
корты
Янымда без-зләп очты.

Нур ГАЙСИН.



В. И. Ленинның Казандагы музей-йортында. Н. Седов фотосы.

Төзелеш батырлары

Ерак Карелиягә күченеп килгәч, башта палаткаларда торырга туры килде. Ә инде палаткадан гомуми баракка күчкәч, күңелләре үсеп китте. Очсыз-кырыйсыз кара урманнар, санап бетергесез күлләр, мәрмәр ташлы кыялар — һәркайсы кызыктырды аларны. Башкалар белән бергә, кечкенә гәүдәле Әхәт тә бу җирләргә әкренләп күнегә башлады. Малай бик иртә кул астына керде. Әтисе үз ишеләр белән зур-зур агачларны кисеп аудара, Әхәт исә әнисе белән аларны ботак-чатаклардан әрчи иде. Аннары тагы тракторларга ягу өчен шакмак та турадылар.

Инде алар урман хуҗалыгында төпләнеп калу турында сүз йөртә башлаганда, илебезнең изге чикләрен бозып, безгә каршы Германия фашистларының сугыш башлаулары турында шомлы хәбәр килеп төште. Әхәтнең әтисе Солтангәрәй абзыйны сугышка алдылар. Тора-бара рәхимсез сугыш үзенең авырлыгын күрсәтә башлады. Дошман самолетлары урмандагы кечкенә поселокка да бомбалар ташладылар. Янгын һәм җимерелүләр, яраланган һәм үлгән кешеләрне күрү исән калганнарның йөрәкләренә кара кан булып сауды.

Газаплы кышны үткәргәч, Әхәтләр гаиләсе мең бәлаләр белән яңадан туган якларына кайтты. Аларны монда да майлы ботка пешереп каршы алучы булмады. Авылда һәркемнең үз кайгысы үзенә җитәрлек. Әле җиденче класста гына укып йөргән үндүрт яшьлек Әхәткә тормыш арбасының авыр йөген тартырга туры килде.

Ил азатлыгы өчен барган сугышта әтисенең батырларча һәлак булуы турында кайгылы хәбәр алдылар...

Мин аның белән алтмышынчы елда таныштым. Зәй ГРЭСында беренче чиратының беренче блогын төзегән кайнар көннәр иде. Әхәт Хикмәтуллин бригадасы пар казанының аерым буыннарын җыя, ут көлтәләре чәчә-чәчә торбаларны эретеп ябыштыра.

— Эшләр ничек бара? — дип сорадым мин аннан, пар казаннары цехында очрашкач.

— Тик торганыбыз юк. Ләкин менә мәшәкать бик күп...

Хикмәтуллин пар казаннары монтажлауның кыенлыгы, өстә торбалар җыюның җайсызлыклары турында сөйләде. Нидер җитми. Эш әкрен үрчи, уйлыйсы бар, дип куйды ул.

Шуннан соң өч ел вакыт сизелми дә үтеп киткән. Әхәт инде партия сафларына кергән, ул җитәкчелек итә торган бригада исә коммунистик хезмәт бригадасы исемен алган иде. Төзелешнең күп тиражлы газетасында Әхәт Хикмәтуллин бригадасы турында мактау сүзләре укыдым да, ул эшләгән урынга юнәлдем. Мин уртача зурлыктагы бүлмәне хәтерләткән, исәпсез күп торбалардан торган блок (булачак пар казанының бер өлеше) яныннан беркадәр читтәрәк тукталып калдым. Әхәт белән күрешеп, берничә сүз әйтергә өлгермәдем, минем бригадирым:

— Соңыннан... — дип бер генә сүз әйтте дә, китеп тә барды.

Мәйданга мотовоз килеп туктады. Тиздән мотовозга тагылган платформага брезент комбинезон кигән кешеләр менделәр. Нәрсәләрнедер рәткә салдылар. Күрәсең, монда сүзнең кирәге юк. Кешеләр бригадирны аның бер хәрәкәтеннән үк аңлыйлар. Җыючы слесарьлар әлеге шул зур блокны корыч арканнар белән куәтле кран күтәргеченә тага башладылар... Мин бу эшнең озакка сузылачагын күз алдына китереп, якындагы башка участокка киттем. Яңадан килгәндә мотовоз да, блок та, эшчеләр дә җыю мәйданында юк иде инде. Кранчы кыз биектән җиргә карап тора. Мин аңа кычкырдым:

— Кая киттеләр?!

— Алар күптән төп корпуста инде, абый... Икенче соңгармагыз, хәзер космос заманы, — дип көлде кранчы кыз.

Гаять зур, гаять биек төп корпус бинасына барып кердем. Бу чагында блок утыз метр биеклеккә күтәрелгән,



пар казанының соңгы буыны булып үз урынына утырган иде инде. Йөз тонна авырлыкта бит ул блок!

Монтажчылар күчмә кошлар кебек алар. Быел ел башыннан диярлек Хикмәтуллин бригадасының кешеләре Яңа Зәйдән Чаллыга йөреп эшләделәр. Көн саен баруга-кайтуга гына да нихәтле вакыт уза. Ләкин бу кыенлык аларны куркытмый. Биргән вәгъдәне, алган йөкләмәне үтәп чыгарга кирәк. Баштарак төрле детальләр, торбалар җитмәүдән тоткарлыклар туа. Әлеге дә баягы шул материаллар турыннан Әхәтнең какмаган ишеге калмады ул көннәрдә. Җитәкчеләр кайгыртыштылар, материаллар килә торды. Алар бик җаваплы участокта — «Камгэсэнергострой»ның яңа төзелә торган даими поселогын җылыту өчен пар казаннарын монтажлауда — эшлиләр иде. Тырышып-тырышып язын да, җәен дә шунда уздырдылар. Төп җаваплылык Әхәт Хикмәтуллин өстендә булды. Ун елга якын аның белән бергә эшләүче металл кисүче Гафур Гафанов, монтажчы-слесарь Мансур Шәйдуллин, сварщик Сәхия Дәүләтшиналар бригадирның җитди кыяфәтеннән үк аңлыйлар иде.

Көннәр авыша тордылар. Көндәлек хәрәкәт, борчылулар, мәшәкать белән тормыш дәвам итте.

Юбилейга багышланган тантаналы җыелышта башлык Анатолий Филимонович Шейкин үзенең докладында горурланып әйтте:

— ...Әхәт Хикмәтуллин бригадасы чын мәгънәсендә батырлык күрсәтте. Пар казаннарын җыю һәм монтажлауны вакытыннан алда тәмамлады. Яңа Чаллының яшьлеге булган поселоктагы бишәр катлы зур-зур йортларда хәзер җылы, уңайлы. Моның өчен кешеләр безгә тирән рәхмәт белдерәләр. Менә телеграмма...

...Әйе, хәзер инде ГРЭСның икенче чиратында беренче адымнар башланды. Бу адымнарны да Әхәт Хикмәтуллин кебек коммунистлар һәм төзелеш батырлары башладылар.

Сөббух РАФИКОВ.



БУЛАЧАК КОСМОНАВТ. Б. Никольский фотосы. Казан, 2 нче мәктәп.

Рәфгать ӘХМӘТҖАН

ИЛДУСНЫҢ БЕРЕНЧЕ СӘЯХӘТЕ

(Дәвамы. Башы газетабызның 23, 24, 26, 27 нче саннарында.)

Бар арада инде зурлар —
Колхозчылар, инженерлар,
Төзүчеләр, сәгатьчеләр,
Тегүчеләр, сәдәпчеләр,
Утыз җиде укытучы,
Йөз егерме бер сатучы,
Кырык матрос, унөч
танкист,
Дүрт журналист,
ике артист,
Пионерлар, нәниләр бар,
Бишек кошы—бәбиләр
бар.
Тик күренми һичбер
җирдә
Өч мең яшьлек бабай
бер дә.
Эзләгәне табылмагач,
Ихтималы да булмагач,
— Бабакай, — ди
Илдус, — юк ул,
Энең ахры Илдус түгел!
Хызыр күзен челт-челт
йомып,
— Шулайдыр, — ди, —
гөнаһ шомлык!
Алай икән... Теге синең
Карт атаең ничек дидең?
Шул исем бик таныш
сизелә,
Бәлки шулдыр, шуны
эзлә.
Ташлый Илдус
Илдусларны,
Эзләп карый Юнысларны—
Менә кайда эшнең шәбе:
Юнысларның юк исәбе:
Идел буе игенчесе,
Азербайҗан диңгезчесе,
Төркиянең батраклары,
Мисыр, Судан
фәллахлары,[1]
Нигерия солдатлары...
Ул гынамы — аннан ары
Шәйләнәләр сансыз
йөзләр —
Исемдәшлектә игезләр:
Йонас, Йон, Джон, Иван,
Иоан, Иоһан, Юһан, Жуан,
Жаннар, Яннар,
Ованеслар —
Асылда бар да Юныслар.[2]
Хәйран Илдус, бабасына
Адаш икән ярты дөнья!
Багып күргәч кайнап
торган,
Йөзләп телдә шаулап
торган
Бу җыенны, бу мәхшәрне
Илдус мәгълүм итә хәлне:
— Юныслар бит хәтсез!
Ничек
Юныслар диңгезен
кичик? —

1 Фәллах — гарәп илләрендә игенче, крестьян.
2 Асылда бар да Юныслар— саналган исемнәр һәм Юныс исеме дә борынгы яһүди (еврей), исемнәренең берсеннән килә.

Гомер буе торба карап
Чыгалмассың аны барлап.
Аптырап, пеләш һәм
кызыл
Башын кашып торды
Хызыр,
Каш җыерып, җиргә
карап,
Мыек чәйнәп, сакал тарап.
Тик бераздан телгә килеп
Әйтте бабай: — Күп
изгелек
Иттең, улым. Хәзер кирәк
Хушлашырга. Сиңа бүләк
Булыр минннән дурбин
белән
Оча торган иске җилән.
Кичер, улым, хаталаныл,
Үзем белән йөрттем алып.
Хәзер оч өеңә табан,
Кайгырмасын атаң-анаң.
Бу сүздән соң, яшен
сыман,
Малаебыз күз алдыннан
Үтте төрле манзаралар:
Кайтып төшкәч ничек
аңар
Карап, кемнәр
көнләшәчәк,
Кемнәр пыш-пыш
сөйләшәчәк,
Ничек аңа заказ килер
Һәм ул шундук табып
бирер
Яшерелгән хәзинәне,
Ничек дәрес әзерләве
Һәм сынаулар җиңел
булыр:
Торба җавап бирел
торыр...
Шулай уйлап безнең
Илдус
Хызыр картка төшерде
күз,
Тик кызыллык алды аны,
Сул култыгы сулкылдады.
Калдыр, имеш, аны
монда —
Кола сахра уртасында —
Кайгы баскан ялгыз
картны,
Мәҗнүн картны, юлсыз
картны!
Һәм ул шунда туры карап,
Ныклы итеп бирде җавап:
— Юк, юк, бабай, җир
йөзендә
Ун мең Илдусның берсе дә
Ташлап качмас үз
юлдашын —
Башка мондый сүз
буямасын!

АЛТЫНЧЫ БАБ
КҮМЕЛГӘН КАЛАЛАР ЧЫҢЫ...

Күпләр белә: зур чүлләрдә
Сәяхәт итеп йөргәндә,
Горизонтта зур калалар—
Күренәләр, югалалар.
Шул ук сахра-
чүлләрдә бар
Көйле комнар, җырчы
комнар —
Җилдә аваз биреп алар
Гүя шулай масаялар:
«Белә тарих: безнең аста
Нинди горур илләр ята!
Бетте алар, күмелделәр
Һәм җир белән
тиңелделәр...
Сызыйк үлгән илләр
моңын,
Күмелгән калалар
чыңын...»
Барханнарның шундый
берсе,
Бабай яткан җиргә
күрше —
Үзәнлектә борын чөеп
Тора иде шактый биек.
Булмасмы, дип, берәр
табыш,
Илдус шуңа карап бер
буш
Кичне китте дурбин
тотып,
Һәм барханга барып
җитеп,
Менеп алгач түбәсенә,
Берегеп катты торбасына:
Ачылды бер сәер
күренеш —
Ком астында шаулый
тормыш:
Шәһәр. Базар.
Кайный халык,
Нәрсәнедер, дулкынланып,
Сөйли бар да бер-берсенә,
Карап кояш сәгатенә,
Таш түгәрәктән ул сәгать
Һәм таш казыктан
гыйбарәт,
Угы — казык күләгәсе,
Хәзерләнәләр һәммәсе
Искиткеч зур хадисәгә,[1]
Беленми тик — нинди
сәбәп...
Куалыйлар төркем-төркем
Кешеләрне төртеп-төртеп,
Аңлап алды Илдус:
коллык!
Гаҗәп булган
борынгылык!
Кинәт кулдан төште торба,
Ком өстендә Илдус тора—
Баш очында йолдыз яна,
Дөнья иске һәм яп-яңа:
Кеше — бала булган элек,
Шуннан үскән һәм
кешелек
Хәзер инде була балигъ,[2]

1 Хадисә — күренеш, вакыйга.
2 Балигъ булу — акылга утыру, җитлегү, өлгерү.

Нинди кызык нәрсә —
тарих!
Кичен уяу ятты озак
Илдус менә шуны уйлап.
Инде йоклыйм дигән
чакта
Ишетелде бик ерактан
Өзек-өзек бер моңлы көй,
Сазлы, курайлы, чыңлы
көй.
Илдус чыкты чатырыннан,
Ләкин көлсу-мамык томан
Япкан иде чүл өсләрен,
Ай нурында көмешләнеп
Ята иде ак дулкыннар
Офыккача катар-катар.
Күренмәгәч башка нәрсә,
Илдус, шүрләсә дә гәрчә,
Уятмыйча гына картны
Китте — кызыксыну
тартты.
Чүлгә колак сала-сала
Бераз баргач алга таба,
Якынайды тавыш. Шунда
Томан пәрдәсе артында —
Күләгәләр шәйләнделәр,
Ишетелде сөйләшүләр,
Чыкты калкып бокра[1]
башы:
Кәрван килә икән каршы.
Үркәчләргә түкләр төяп
Тау-тау итеп, йөзләп дөя
Тезелешеп, салмак атлап
Адым саный, ике яклап
Чаптар-тази[2] атлар менеп
Кисәк-кисәк чабып, җилеп
Килә кәрван сакчылары,
Сөңге болгый кайсылары.
Кайсы курай уйнап килә,
Кайгылы көй моңлап
килә.
Ә иң алдан качыр менгән,
Чалма урап, чапан кигән
Кәрван башы — кара
гарәп
Тирә-юньне бара карап.
Менә ул бик кискен генә
Күтәрелде өзәңгедә —
Илдусны ул күреп алды,
Бармак төртеп сөрән
салды.
Өерелде чос сакчылар,
Күрә Илдус: тотмакчылар,
Китте качып: дөп-дөп
йөрәк!
Китәлмәде ләкин
ерак —
Мәргән кулдан озын

1 Бокра — ата дөя.
2 Тази ат — гарәп токымыннан булган юртак ат.

корык[1]
Эләктерде аны шундук,
Килеп тотты көчле
куллар,
Киертелде кулга коллар
Өчен булган бөҗра-балдак,
Кәрван башы тартып
бәйләп
Куйды аны канҗырына,[2]
Менгәштереп[3] качырына.
Дәвам итә кәрван юлын,
Кузгаталмый Илдус кулын
Ләкин качыр
савырыннан,[4]
Кара гарәп яурыныннан[5]
Алга карый үрелгәләп.
Менә берчак күренәләр
Алда биек манаралар,
Тирән урай,[6]
таш диварлар —
Вади[7] томаныннан калка
Мәһабәт зур, ныклы
кальга.
Кәрван кальга
капусында —
Халык чыга каршысына,
Яктырталар фитилә белән,
Төшерелә күтәрелгән
Күпер,
кәрван әкрен генә
Капу ачымыннан керә.
Халык.
Ләкин һич шау-шу юк,
Күзләр моңсу, бар да
боек.
Килеп чыга патша үзе —
Акрын сүзе, уйчан йөзе.
Кәрванчылар төшәләр дә
Атларыннан, дөяләрдән,
Аңа барып баш иәләр,
Товар-түкләр чишеләләр.
Бер уңайдан кемдер
шунда
Ычкындыра Илдусны да,
Кәрван башы күреп тора,
Селти, ләкин, кулын
гына.
Сикереп төшә Илдус
җәһәт,
Куллар азат —
нинди рәхәт!
Кинәт — күлмәк
җиңеннәнме,
Тишек кесә төбеннәнме —
Тәңкә төшә чылтырт итеп,
Ай нурында елтырт итеп.

1 Корык — очына элмәкле аркан беркетелгән колга — көтүдәге малны тоту яки дошман сугышчысын аттан тартып төшерү өчен кулланылган.
2 Канҗыр — ияргә беркетелгән киндерә.
3 Менгәштерү — атка, ишәккә һ. б. үзеңнән артка утырту.
4 Савыр — ат яки ишәк торыгының арткы өлеше,ияр арты.
5 Яурын — кулбаш арты.
6 Урай — кальга тирәли казылган тирән канау.
7 Вади — чүлдәге коры үзән.



БЕЗНЕҢ АДРЕС: г. Казань, ул. Баумана, 19. Редакция газеты «Яшь ленинчы». ТЕЛЕФОННАР: редактор — 2-56-71; җаваплы секретарь — 2-60-05; әдәбият-сәнгать, хатлар бүлекләре — 2-17-78; пионерлар һәм мәктәп, фән-техника һәм спорт бүлекләре — 2-47-30. Редактор В. ИХСАНОВА.

ПФ 00196. Заказ 1064. Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Тиражы — 100500.